

Мордовия Госсобрание рәисе Владимир Чибиркин Ромодан районында эш сәфәре кысаларында булган.
Мордовия Дәvләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин «Ромодановосахар» директоры, Мордовия Дәvләт Жыены депутаты Александр Атласов белән бергә, ТЭЦны реконструкцияләvнен ничек баруын караганнар.

Хәзер анда vзебезнен яна жиһазлар урнаштыралар: бу эшнен ышанычлылыгын арттырып кына калмыйча, ахыргы продукциянен vзкыйммәтен дә киметәчәк.  Заводта Владимир Чибир-кин коллектив белән дә аралашкан. Предприятие эшчәнлеге турында фикер алышканнар. Cvз шулай ук Ромодан районында якын арада хәл ителәчәк мәсьәләләр, шул исәптән тозекләндерv буенча да булган.
Мордовия Дәvләт Жыены рәи-се булган vтенечләрне һәм те-ләкләрне шәхси контрольгә алган. Әлеге предприятиядә кvп кенә милләттәшләребез тырышып хезмәт итә, шул исәптән алар да теләкләрен ишеттергәннәр.
Әйтеп китәргә кирәк, «Ромодановосахар» - Идел буендагы ин эре тармак предприятиесе, житештерv кvләмнәрен арттыруны дәвам итә. Узган сезонда биредә 885 мен тоннадан артык чимал эшкәртелгән һәм 138 мен тоннадан артык шикәр житештерелгән, ул торле тобәкләргә экспортка чыгарыла. Үсеш дәвам итә.

**Наилә НАСЫРОВА,**
**Фото: РМ Госсобраниесе сайтыннан**